**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.08.2024 — № 988

«Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Нурлат муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 380 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдиме нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 380 номерлы карары белән расланган (2022 елның 01 августындагы 819 номерлы кертелгән үзгәрешләр белән) мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 1 пунктын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче — Ә.К. Габдуллин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 29 августындагы 988 номерлы карарына кушымта

II. Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренә база окладларын билгеләү

1. Нурлат муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең нигез окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем бирү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18405,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18410,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек мөдире (җитәкчесе) урынбасары: муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек;<br>Структур бүлек мөдире (бүлек): муниципаль берәмлекләрнең мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек; | - | - | 18481,0<br><br>18550,0 |